ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛЫ ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ
КАРАР

29 ноябрь 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Енабердино авыл
җирлегенең Енабердино авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләлре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2024 елның 19 ноябрендәге 5 номерлы карары нигезендә, 2024 елның 29 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 227 катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 126 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 126 катнашучы тавыш бирде, «каршы» позициясе өчен җыенда - 0 тавыш. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. "2025 елда үзара салымны Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары уку йортларының һәм урта махсус уку йортларының көндезге бүлеге студентларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан салымны 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорауны расларга.

   1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Енабердино авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру).

   2) су белән тәэмин итү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны,

транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Енабердино авылында насос сатып алу).

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Енабердино авылындагы юлларны кардан чистарту). Енабердино авылында вак таш сатып алу, ташу, тигезләү).

4) торак пункт территориясен төзекләндерү (Енабердино авылында үлән чабу, Енабердино авылында авария хәлендәге агачларны кисү хезмәтләре)

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру 1данә.»

3. Әлеге карарны махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә  урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Ю.Скворцова